| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2021 с.Старое Дрожжаное № 391

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү Советын төзү турында

Чүпрәле муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы ирекле ярдәмчелек берләшмәләре (волонтерлар) эшчәнлеген үстерү һәм аларга ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү буенча Совет төзергә.

2. Расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү Советы турында Нигезләмә (1 нче кушымта).

2.2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү Советы составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Башкарма комитетының
"09" 09 2021 № 391
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны)
үстерү Советы СОСТАВы

Җәләлов А.Ф. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

Вилданов Р.Р. –Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, Совет рәисе урынбасары;

Нурутдинова Э. Р – Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге әйдәп баручы белгече, Совет секретаре.

Совет Әгъзалары:

1. Халитов И.А. - «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;
2. Сәгъдиев З.Ф. - «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы;
3. Йосыпова З.И. - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Чүпрәле муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);
4. Шиһабетдинов И.И. - «Чүпрәле РҮХ» ГАУЗ баш табибы (килешү буенча)
5. Рәкыйпов И. А – Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе;
6. Романова Е.А.- “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Созидание” яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы” муниципаль бюджет учреждениесе директоры вазыйфаларын башкаручы;
7. Вәлиуллин И.И. - Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «ФОРПОСТ» МБУ директоры;
8. Җамалетдинова Р. Р. – «Туган як» газетасы мөхәррире (килешү буенча);

Башкарма комитет
эшләре идарәчесе: Д. Р. Сабирҗанова

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының "09" 09 2021 № 391 карары белән РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү Советы турында
Нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында (алга таба - Совет) ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү Советы Җирле үзидарә органнарының килешеп эшләвен һәм аларның ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсендә иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырылган консультатив орган булып тора.

1.2. Совет үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Советның максатлары һәм бурычлары

2.1. Совет эшчәнлегенең төп максаты-Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелеккә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге субъектларының нәтиҗәле хезмәттәшлеген оештыру.

2.2. Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында җирле үзидарә органнары һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү һәм аны үстерү мәсьәләләре буенча ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) субъектлары эшчәнлеген координацияләү;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) өстенлекле юнәлешләренә ярдәм итү һәм ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

- ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенең төп юнәлешләре (мәгариф, сәламәтлек саклау, гражданлык-патриотик тәрбия, мәдәният, социаль ярдәм һәм халыкка социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт, әйләнә - тирә табигатьне саклау, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, Эчке эшләр органнарына ярдәм итү, вакыйгалар, инклюзив, корпоратив иреклелек (волонтерлык), өлкән яшьтәге гражданнарның ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге - «Көмеш волонтерлык»;

- Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә комплексы анализ ясау.

3. Совет вәкаләтләре

Совет үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1. Дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан Совет компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга;

3.2. Совет әгъзаларының берсе җитәкчелегендә Совет әгъзалары арасыннан, Совет бурычларын һәм функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне хәл итү өчен, вакытлы һәм даими эшләүче эшче төркемнәр төзү.

4. Совет эшчәнлегенең составы һәм оештырылуы

4.1. Совет составы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.2. Совет рәисе, Совет рәисе урынбасары, Совет секретаре һәм Советның башка әгъзалары составында формалаша.

Совет составында агымдагы эшне оештыру өчен төп эшчәнлек юнәлешләре буенча комиссияләр (эшче төркемнәр) төзелергә мөмкин.

4.3. Совет рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, совет утырышларын уздыра, Совет эшенең планын раслый, Совет әгъзалары арасында аңа йөкләнгән бурычлар һәм функцияләр кысаларында бурычлар бүлә, Совет әгъзаларына тиешле йөкләмәләр бирә, беркетмәләргә һәм Советның башка документларына кул куя.

4.4. Совет рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Совет рәисе кушуы буенча Совет рәисе урынбасары башкара.

4.5. Совет утырышлары кирәк саен үткәрелә, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Совет утырышында әгъзаларының гомуми санының кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Советның утырышларына материаллар Советның секретаре тарафыннан Совет утырышын уздыру датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча таратылырга тиеш.

4.6. Совет Әгъзасы Совет утырышларында шәхсән катнашырга тиеш. Утырышта катнашу мөмкин булмаган очракта, Совет әгъзасы бу хакта Совет рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

4.7. Совет утырышларында тикшерелә торган мәсьәләләр Совет карары белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашучы гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә, утырышлар беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, алар Совет рәисе тарафыннан имзалана. Тавышлар саны тигез булганда Совет рәисе яисә Совет утырышында рәислек итүче Совет рәисе урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.

4.8. Совет утырышы йомгаклары буенча беркетмәләр утырыш уздырылган көннән 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм Совет рәисе кул куйганнан соң өч көн эчендә Совет әгъзаларына, кызыксынган республика башкарма хакимияте

органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә җибәрелә.

4.9. Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү, шулай ук халыкны ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп итү өчен җаваплы булып Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тора.

4.10. Советның үз компетенциясе нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерына ия.

Башкарма комитет
эшләре идарәчесе: Д. Р. Сабирҗанова